**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге составына керүче Яңа Татар Әдәмсуы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

**2021 елның 25 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы» Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 ст., "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 90 номерлы карары нигезендә

Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Яңа Татар Әдәмсуы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1.**Яңа Татар Әдәмсуы авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:**

- Яңа Татар Әдәмсуы торак пунктында вак таш сатып алу
- вак таш җәю буенча эшләр башкару;
- кышкы юлларны карап тоту (килешү буенча түләү).

2. **Авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итү;**

- янгын сүндерү машинасын карап тоту, ягулык-майлау материаллары сатып алу.

3. **Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;**

-Яңа Татар Әдәмсуы торак пунктында үлән чабу (килешү буенча түләү).

"ӘЙЕ" "ЮК" "ТОТКАРЛАНУЧЫ" " мәсьәләсе буенча 2021 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә граждannar җыенында катнашучы 42 кеше, тавыш бирүдә катнашкан граждannar саны 26 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
- «әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 26 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
- «тоткарланучы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **КАРАР** итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге составына керүче Яңа Татар Әдәмсуы пунктында граждannar җыенын узган дип таныргa, граждannar җыены нәтиҗәләре - чын мәгънәсендә.

2 Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Яңа Татар Әдәмсуы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?;

1.**Яңа Татар Әдәмсуы авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:**
- Яңа Татар Әдәмсуы торак пунктында вак таш сатып алу
- вак таш җәю буенча эшләр башкару;
- кышкы юлларны карап тоту (килешү буенча түләү).

**2. Авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итү;**
- янгын сүндерү машинасын карап тоту, ягулык-майлау материаллары сатып алу.

**3. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;**

-Яңа Татар Әдәмсуы торак пунктында үлән чабу (килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм http://pravo.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы
авыл җирлеге башлыгы Э.М.Хөснуллина